“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”
муниципаль мәктәпкәчә белем учреждениесе

Гыйнвар, 2025 нче ел

# Чишмә башы

Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча газета

## Тагын килегез!

**Кышкы каникулларны барыбыз да зарыгып көтеп ала. Нәкъ менә әлеге әкияти ел фасылында яллар аеруча күңелле һәм рәхәт үтә. Кышкы каникулларда балалар ялын оештыруда безнең балалар бакчасы хезмәткәрләре дә үз өлешләрен керттеләр. Тәрбиячеләр 5 нче гыйнвар көнне Арча үзәк стадионы мәйданчыгында «Яңа ел маҗарасы» исемле күңелле тамаша оештырдылар. Балалар Убырлы белән бау тартыштылар, Кар бабайга кар тупларын җыерга булыштылар. Кар кызы белән Кыш бабай балаларны Яңа ел белән котлап, бәйрәм күчтәнәчләре өләште.**









## 2025 нче ел — “Ватанны саклаучылар» елы




**Россия Президенты Владимир Путин 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәргә тәкъдим итте. «Киләсе елда без Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Шуңа бәйле рәвештә 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәргә тәкъдим итәм», – диде дәүләт башлыгы РФ Дәүләт Советы утырышында. Искәртик, сентябрьдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шулай ук 2025 елны республикада Ватанны**




## Уртак эш тау күчерә

Илдә барган хәл-вакыйгалар беркемне дә битараф калдырмады. Мобилизацияле солдатларга ярдәм җыю кысаларында безнең балалар бакчасы хәйрия акциясендә катнашты. Ярдәм җыюда хезмәткәрләр үзләре, тәрбияләнүче балалар һәм аларның әти-әниләре катнашты. Алар азык-төлек, җылы әйберләр, шәхси гигиена кирәк-яраклары җыйды, ә балалар педагог белән бергә хәрбиләр өчен хатлар язды, яхшы теләкләр белән открыткалар ясады. Балалардан посылка чираттагы гуманитар йөк составына кертелеп, ерак юлга озатылды. Аларга хәерле юллар телибез!









## Күңелле каникуллар

**Кышкы каникуллар - күңелле Яңа ел бәйрәмнәре, кызыклы очрашулар, мавыктыргыч конкурслар, уеннар, ярышлар белән үрелеп бара. Ял вакытында балалар рәхәтләнеп саф һава суладылар, спорт уеннары уйнадылар, бәйрәм бүләкләре кабул иттеләр. Ата-аналар белән бергә узган бу вакыт бары тик күңелле хәтирәләр генә калдырыр дип ышанасы килә.**










***Газетаны оештыручы мөхәррир:*** *Камалиева Гөлназ Рәис кызы*